ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.08.2022 г. Заинск № 390

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан белем бирү оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыкка каршы якланганлыгын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү бәясе нормативларын раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы объектларының (территорияләренең) һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы эшчәнлеге өлкәсенә караган объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы яклануына таләпләрне һәм әлеге объектларның (территорияләрнең) иминлек паспорты рәвешен раслау турында» 2019 елның 02 августындагы 1009 номерлы карарын, «Татарстан Республикасы мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә куркынычсызлыкны тәэмин итү турында» 2022 елның 16 мартындагы 6-273-6 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын, «Шәхси сак оешмаларыннан аларны сатып алуны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыкка каршы якланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү нормативларын билгеләү тәртибе турында методик рекомендацияләрне раслау хакында" 2021 елның 23 ноябрендәге 1112 номерлы, "Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмалары объектларының (территорияләренең) территорияләренең) террорчылыктан яклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр хакының нормативларын раслау турында, аларны хосусый сак оешмаларыннан сатып алганда, һәм 12 сәгатьлек эш режимы белән саклау постлары санын билгеләү хакында» 2021 елның 24 ноябрендәге 1114 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын, «Методик рекомендацияләр җибәрү турында» 2020 елның 10 апрелендәге ЛБ-С-088-8929 номерлы РФ Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы хатын үтәү йөзеннән, Зәй муниципаль

районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан белем бирү оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыкка каршы якланганлыгын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү бәясе нормативларын расларга (кушымта).

2. 1 пост-сәгатьнең бәясен билгеләгәндә 2021 елның 23 ноябрендәге 1112 номерлы карар нигезендә методик рекомендацияләргә, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең 2021 елның 15 февралендәге 45 номерлы боерыгына, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2017 елның 16 июнендәге 24-01-10/37713 номерлы хатына таянып эш итәргә.

3. Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан белем бирү оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан яклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү буенча бюджет акчаларын нәтиҗәле файдалану максатыннан, балалар белем бирү оешмасында булганда объектларны саклау махсус сак оешмасы көче белән, балалар булмаган чорда (төнге вакыт, ял, бәйрәм көннәре һәм каникуллар чорында) белем бирү оешмасының штат расписаниесендә каралган штат берәмлекләре ярдәмендә башкарыла.

4. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә түбәндәгене тәэмин итәргә:

белем бирү оешмаларын белем бирү оешмалары обектларының (территорияләренең) террорчылыкка каршы яклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр хакының исәп-хисабы нигезендә финанслауны.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 04.08.22 390 номерлы карары белән расланды.

**Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан белем бирү оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү бәясе нормативлары**

Контрактның башлангыч (максималь) бәясе муниципаль контактның башлангыч (максималь) бәясен билгеләү ысулларын куллану буенча методик тәкъдимнәр нигезендә муниципаль заказчы тарафыннан исәпләнгән.

| № | Контракт предметының исеме | Үлчәү бер. | Саны | Коммерция тәкъдимнәре (сум) | | | Н(М)ЦК, ЦКЕП хисабында кулланыла торган ачыкланган бәяләр күрсәткечләренең бер төрлелеге | | | Чагыштырма базар бәяләре ысулы белән билгеләнә торган (базарны анализлау)*Н(М)ЦК, ЦКЕП | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Тәэмин итүче №1, Чыгу № 90 28.12.2021 ел, сум. | Тәэмин итүче №2, Чыгу № 391 28.12.2021 ел, сум. | Тәэмин итүче №3, Чыгу № 58 28.12.2021 ел, сум. | Бер берәмлек өчен уртача арифметик бәя <ц> | Уртача квадрат тайпылыш $\sigma = \sqrt{\frac{\sum_{i=1}^{n}(ц_i - <ц>)^2}{n-1}}$ | Бәяләр вариациясе коэффициенты V (%) *(33%тан артырга тиеш түгел)* $V = \frac{\sigma}{<ц>} * 100$ | Н(М)ЦК хисабы түбәндәге формула буенча v - сатып алына торган товарның (эш, хезмәт күрсәтүләрнең) саны (күләме); n - исәпләүдә кулланыла торган күрсәткечләр саны; i - бәя мәгълүматы чыганагы номеры; $ц_i$ - берәмлекнең бәясе $НМЦК^{рын} = \frac{v}{n} * \sum_{i=1}^{n} ц_i$ | Үлчәү берәмлеге өчен бәя (сум) | Өтердән соң йөзенче өлешләргә кадәр түгәрәкләп, үлчәү берәмлеге өчен бәя (сум) | Н(М)ЦК, ЦКЕП бер берәмлеккә бәяләрне түгәрәкләүне исәпкә алып контракт (сум) |
| 1 | Сак хезмәтләре күрсәтү | сәг. | 1 | 220,00 | 222,00 | 250,00 | 230,67 | 16,77299417 | 7,271529263 | 230,67 | 230,67 | 230,67 | 230,67 |
| | | | | | | | | | | | | **Барысы** | **230,67** |

**НМЦК (НМЦ бер берәмлек өчен кабул ителгән (сак хезмәтләре күрсәтү) 220 сум тәшкил итә, НЦМКрын 1*220,00 = 220,00 сум.**
**Бюджет акчаларын экономияләү максатыннан, бәя Россия Финанс министрлыгының 2017 елның 16 июнендәге 24-01-10/37713 номерлы хаты нигезендә минималь коммерция тәкъдиме дәрәҗәсендә билгеләнде.**